**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Дубъязы, ул. Ленина, 28

тел./факс 8(84365) 61-2-86, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 июль 2022 ел** **№ 52**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып,Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 150номерлы карары белән кабул ителгән (Советның 07.08.2020 №168, 15.01.2021 №17 карарлары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын федераль һәм региональ законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советы карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Советы карары проекты буенча килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта оештыру комитеты (алга таба -

Оештыру комитеты) төзергә:

1) Галиуллин Р.Ш. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге башлыгы, оештыру комитеты рәисе;

2) Бариев И.Ф..– Дөбьяз авыл җирлеге Советы депутаты - оештыру комитеты рәисе урынбасары;

3) Латыйпов Л.И. – Дөбьяз авыл җирлеге Советы депутаты - оештыру комитеты әгъзасы.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча 2022 елның 09 августына 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Дөбьяз авылы, Ленин ур., 28 йорт адресы буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

5. Гавами тыңлаулар уздыру буенча оештыру комитетына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне, исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Дөбьяз авыл җирлегенең Дөбьяз авылы, Ленин ур, 28 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмати стендында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Галиуллин

1 нче кушымта
Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2022 елның 18 июле № 52карарына

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЬЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Дубъязы, ул. Ленина, 28

тел./факс 8(84365) 61-2-86, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**____________, 2022 ел** **№ ___**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын федераль законнар нигезләмәләрен төгәл кабатлау формасында тәңгәл китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 150 номерлы карары белән кабул ителгән (Советның 07.08.2020 №168, 15.01.2021 №17 карарлары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **6 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 21 пункт** белән тулыландырырга:

«21) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча карарлар кабул итү һәм чаралар уздыру, күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен әлеге күчемсез милек объектларының хокук ияләре турында белешмәләр җибәрү.»;

2) **21 статьяның 10 һәм 11 өлешләрен** яңа редакциядә бәян итәргә:

«10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе Җирлек Уставы һәм (яисә) Җирлек Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә һәм муниципаль берәмлек халкына гавами тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән, шул исәптән аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль

районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән дә алдан ук таныштыруны яисә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми сайтында яисә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында (алга таба әлеге статьяда - рәсми сайт) үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, фикер алышуга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча муниципаль берәмлек халкының үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен җиткерү мөмкинлеген, шул исәптән рәсми сайт ярдәмендә, муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларында катнашуын, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә торган башка чаралар, кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләүне дә кертеп, шул исәптән аларны рәсми сайтта урнаштыру юлы белән таныштыруны күздә тотарга тиеш.

Җирлек Уставы һәм (яисә) Җирлек Советы норматив хокукый актлары белән, әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән материалларны һәм мәгълүматны урнаштыру, муниципаль берәмлек кешеләренең муниципаль хокукый акт проекты буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен тапшыру мөмкинлеген тәэмин итү өчен, шулай ук гавами тыңлауларда, рәсми сайтның мондый максатлар өчен мәҗбүри файдаланылуы турындагы таләпләрне үтәп, муниципаль берәмлек халкының катнашуы өчен, әлеге статьяның максатлары өчен аны файдалану тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән "Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы файдаланылырга мөмкин дип билгеләнергә мөмкин.

11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, җирләрдән файдалануның һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә уздырыла.»;

3) **24 статьяда:**

а) 1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 абзацлар белән тулыландырырга:

«-җирлек составына керә торган торак пункт территориясе өлешендә Татарстан Республикасы законы нигезендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

-авыл халкының тыгызлыгы түбән булган яисә барып җитәргә кыен җирдә урнашкан җирлектә, әгәр авыл җирлеге халкының саны 100 кешедән артмаса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

б) 3 өлештә «торак пунктта яшәүче тавыш бирү хокукына ия халыкның яртысыннан күбрәге анда катнашканда» сүзләреннән соң (яисә аның территориясенең өлешләре) сүзләрен өстәргә.».

в) түбәндәге эчтәлекле 3.1. өлеш белән тулыландырырга:

«3.1. Гражданнарның җыены торак пункт территориясенең бер өлешендә торак пункт территориясенең җирлек составына керүче әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Мондый гражданнар җыены Дөбъяз авыл җирлеге Советы тарафыннан торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәгән 10 кешедән ким булмаган төркем инициативасы белән чакырыла.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясе чикләре җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләләрне хәл итүдә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре бердәмлеге критерийларыннан чыгып, Дөбъяз авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнә.»;

4) **42 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яки яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ булу, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

5**) 45 статьяның 5 өлешенә** түбәндәге эчтәлекле **икенче абзац өстәргә**:

«Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, яки чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) сатып алуы яки яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ алуы турында муниципаль берәмлек башлыгына язма рәвештә, аңа бу турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктаткан яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданствосын) сатып алган йә әлеге пунктта каралган яшәүгә рөхсәт яисә башка документ алган көннән биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә бурычлы.»;

6) **48 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яки яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ булу, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

7) **51 статьяның 3 өлешендәге 8 абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына»;

8) **59 статьяның 3 өлешендә**:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил дәүләте гражданлыгын (подданствосын), аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, туктату турында муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы), аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт белән тулыландырырга:

«9.1) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) сатып алу йә яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алуы турында, муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, әмма чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) алынган көннән, яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

9) **77 статьяны тулыландырырга**:

а) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш белән:

«3.1. Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру белән бәйле муниципаль норматив хокукый актлардагы мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү тәртибе һәм аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль, административ җаваплылыкка тарту, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр бирү, аккредитацияләү, бәяләү һәм экспертизаның башка формалары рамкаларында (алга таба - мәҗбүри таләпләр), «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән

мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм бәяләү принципларын исәпкә алып, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш белән:

«4. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар проектлары Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан уздырыла торган җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиеш.

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла»;

10) **88 статьяда:**

а) 7 өлештә:

- түбәндәге эчтәлекле өченче яңа абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгели торган документлар;»;

- өченче - җиденче абзацларны ярашлы рәвештә дүртенче - сигезенче абзацлар дип санарга;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 өлеш белән тулыландырырга:

«19. Дөбьяз авыл җирлеге бюджетының состав өлеше сыйфатында аерым торак пунктларның, муниципаль берәмлекләр булмаган башка территорияләрнең керемнәре һәм чыгымнары сметалары каралырга мөмкин»;

б) 19-20 өлешләрне тиешенчә 20-21 өлешләр дип санарга;

11) **99 статьяның 2 өлешен:**

а) «шулай ук» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзләрне өстәргә: «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru)»;

б) түбәндәге эчтәлекле дүртенче яңа абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль берәмлек башлыгы теркәлгән муниципаль берәмлек Уставын, муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актын, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы идарәсеннән устав, уставка үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставлары дәүләт реестрына кертү турында хәбәрнамә кергән көннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбьяз авылы., Ленин ур, 28 (авыл җирлегенең административ бинасы), махсус мәгълүмати стендларда, һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Галиуллин

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2022 елның 18 июлендэ №52 карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу Тәртибе һәм Гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу**
**ТӘРТИБЕ**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышуда гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм катнашуның әлеге Тәртибе (алга таба - Тәртип), проект буенча фикер алышуда катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатларында, гражданнарның Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрен кертү тәртибен беркетә.

2. Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге халкы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проектны игълан иткән вакыттан алып аны тикшерүдә түбәндәге формаларда катнашырга хокуклы:

1) яшәү урыны буенча гражданнар җыелышларын үткәрү;

2) әлеге Тәртип нигезендә устав проекты буенча массакүләм фикер алышу;

3) устав проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру;

4) гамәлдәге законнарга каршы килмәгән башка формаларда.

3. Тәкъдимнәр Дөбьяз авыл җирлегенә түбәндәге адрес буенча бирелә: 422720, Биектау районы, Дөбьяз авылы, Ленин ур., 28 йорт, телефон 8(843)6561286.

4. Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урынын күрсәтеп имзаланырга (гражданнар өчен), юридик затлар, иҗтимагый оешмалар, берләшмәләр өчен - юридик адресы, җитәкчесенең имзасы һәм имзасының аңлатмасы мөһер белән таныкланырга тиеш.

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында басылып чыккан проект буенча өстәмәләр һәм (яисә) үзгәрешләр турында халык тарафыннан гавами тыңлауларда күрсәтелгән тәкъдимнәр (алга таба - тәкъдимнәр) гавами тыңлауларның йомгаклау документында күрсәтелә, ул Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча оештыру комитетына (алга таба - эшче төркем) тапшырыла.

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл

җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) проектка халыкның тәкъдимнәре эш төркеменә басылып чыккан көннән алып 20 көн эчендә кертелә һәм әлеге Тәртип нигезендә аның тарафыннан карала.

6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәр актив сайлау хокукына ия Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан кертелергә мөмкин.

7. Граждан (гражданнар төркеме) устав проекты буенча әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә тәкъдимнәрне рәсмиләштерә һәм аларны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча эш төркеменә җибәрә.

8. Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Советы депутатлары Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәрне Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә кертәләр.

9. Кертелгән тәкъдимнәр эшче төркем тарафыннан теркәләләр.

10. Тәкъдимнәр Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары таләпләренә туры килергә тиеш.

11. Тәкъдимнәр түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

1) устав проекты нигезләмәләренең бер мәгънәле аңлатмасын тәэмин итәргә тиеш;

2) устав проектының башка нигезләмәләре белән каршылыкка яисә килешмәүгә юл куймаска.

12. Әлеге Тәртиптә каралган таләпләрне һәм срокларны бозып кертелгән тәкъдимнәр каралмыйча калдырылырга мөмкин.

13. Кертелгән тәкъдимнәрне өйрәнү, анализлау һәм гомумиләштерү йомгаклары буенча эшче төркем бәяләмә төзи.

14. Кертелгән тәкъдимнәргә эшче төркем бәяләмәсендә түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны;

2) әлеге Тәртип нигезендә каралмыйча калган тәкъдимнәр саны;

3) әлеге Тәртип тарафыннан куела торган таләпләргә туры килмәүне күздә тотып кире кагылган тәкъдимнәр;

4) эшче төркем тарафыннан кире кагылуга рекомендация бирелгән тәкъдимнәрне;

5) устав проекты текстына кертү өчен эшче төркем рекомендация биргән тәкъдимнәр.

15. Эшче төркеме Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Советына үз бәяләмәсен һәм, кергән барлык тәкъдимнәрне дә кертеп, эш төркеме эшчәнлеге материалларын тапшыра.

16. Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Советы тәкъдимнәрне кабул итү (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект текстына кертү) яисә тәкъдимнәрен кире кагу турындагы мәсьәләне хәл итү алдыннан эшче төркем җитәкчесенең яки эшче төркемнең вәкаләтле әгъзасының эшче төркем эшчәнлеге турында докладын тыңлый.

17. Кабул ителгән тәкъдимнәрне мәҗбүри үз эченә алган устав проекты буенча гражданнардан кергән тәкъдимнәрне карау йомгаклары халыкка игълан ителергә тиеш.

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында фикер алышуда гражданнарның тәкъдимнәрен һәм катнашуларын исәпкә алу Тәртибенә

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында проект буенча, аны тикшергәндә гражданнар кертә торган тәкъдимнәр**

| № | Пункт, пунктча, статья | Устав проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып устав проекты тексты | Төзәтмә кем тарафыннан кертелгән |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәр керткән граждан (гражданнар төркеме) турында мәгълүматлар**

| | |
|---|---|
| Тәкъдимнәр керткән гражданның (гражданнарның) фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Өй адресы, телефоны | |
| Шәхесне таныклый торган документ турында мәгълүматлар | |
| Эш, уку урыны | |

Гражданның (гражданнарның) имзасы Дата